

# Юлдаш

№ 5
Декабрь

## Баш редактор сүзе

Ак карлары, буراннары белән кыш та җитте. Елның соңгы ае – декабрь дә ахырына якынлашып килә. 2024 нче ел вакыйгаларга бай ел булды. Шатлыклар да, борчулар да, уңышлар да күп булды. Укучыларыбыз да төрле ярышларда, конкурсларда, фән олимпиадаларында җиңүче һәм призерлар булып, мәктәбебез данын яклыдылар. Без барыбыз да бер яшькә үстек, акылыбыз һәм көчебез артты. Яңа 2025 нче ел сезгә яңадан-яңа уңышлар, сәламәтлек, күңелле сюрпризлар алып килсен, дөньялар имин булсын. “Юлдаш” газетасын укыгыз, безнең белән бергә булыгыз! Сездән шигырьләр, әкиятләр, мәкаләләр көтеп калабыз.

**Әмир Шафигуллин**



## Иҗат лабораториясе

Әкият

**Кечкенә чыршы зары**

Авылдан ерак түгел урнашкан бер зур һәм калын урманда яшәгән ди бер кечкенә Чыршы кызы. Аның дуслары да бик күп булган. Чыршы кызлары һәм малайлары берсеннән-берсе матур, купшы булганнар. Ә кечкенә Чыршы кызы матурлыгы белән мактана алмаган. Аның ботаклары да кәкре, ылыслары да әз булган. Чөнки ул кечкенәдән үк бик еш авырган ди.

Менә берзаман якындагы авылдан урманга кешеләр еш килә башлаган. Алар иң матур, иң купшы чыршыларны сайлап, үзләренә бәйрәмгә алып китә башлаганнар. Чыршы кызы янына гына берәү дә килмәгән, аның ягына борылып та карамаганнар. Аның да бит кешеләр белән бәйрәм итәсе килгән. Кәефе киткән Чыршы кызы елый башлаган. Бу тавышны ишетеп, Кыш бабай килеп җиткән.



- Нәрсә булды, үскәнем? Ник елыйсың болай?- дигән ул.

- Минем бөтен дусларымны авылга Чыршы бәйрәменә алып киттеләр. Мин генә ялгыз калдым. Мин матур түгел, күлмәгем дә ямьсеееез,- дип тагын да ныграк елый башлаган ул.

Кыш бабай үзенең тылсымлы таягы белән орынуы булган, Чыршы кызы танымаслык булып үзгәргән. Күлмәге дә, үзе дә искиткеч матур булган.

Иртәгесен урманга әти-әнисе белән Гүзәл дә килгән. Алар да бәйрәмгә чыршы эзлиләр икән. Гүзәл шунда ук безнең Чыршы кызын күреп, кычкырып җибәргән:

- Әти, әни, карагыз, нинди матур чыршы!

Кечкенә Чыршының хыялы тормышка ашты. Ул да, дуслары кебек, кешеләр белән бәйрәм итәргә авылга кайтып китте.

**Гаффарова Вәсилә**
**5 сыйныф**
**Татар теленә тәрҗемә - Волкова Р.Ш.**

*Яңа ел - Новый год - New Year - Neujahr - Año Nuevo - Le Nouvel an - Nowy Rok*

*“Кешеләрне һәрвакыт матур эшләрегез, игелекле гамәлләрегез белән сөендерегез”. Татар халык мәкале*

**Үгез һәм Ат**

**Әкият - мәкаль**

Яшәгән ди бер авылда Үгез һәм Ат. Алар бик дус булганнар. Көндез эшләгәннәр, ә кичен ял иткәннәр.

Бервакыт Үгез Атка әйткән:

- Дустым, ярдәм итче миңа. Мин бик ардым. Ә хуҗам ял итәргә дә бирми. Елгадан ике бочка су алып кайтырга кирәк иде.

- Рәхәтләнеп булышам,- дип җавап биргән дусты. Ат тиз генә елгадан суны алып кайта да, Үгезгә бирә. Үгез суны хуҗасына кертә. Ләкин дустына рәхмәт әйтергә оныта.

Икенче көнне алар тагын очрашалар. Үгез әйтә икән:

- Дустым, миңа тагын булыш әле. Көн буе эшләп ардым. Бер хәлем дә юк. Басудан салам алып кайтасы иде.

- Булышам, ник булышмаска? Син бит минем якын дустым, - дигән Ат. Тиз генә басуга барып саламны алып кайткан. Ә Үгез саламны хуҗасына биргән. Атка рәхмәт әйтергә тагын онытканул.

Өченче көнне дә шул ук хәл. Үгез Ат янына килә һәм зарлана башлый.

- Менә эшләдем мин бүген! Көн буе басуда җир сөрдем. Хуҗам кичкә эшне бетерергә кушты. Булыш әле миңа тагын. Син бит минем дустым, - дигән Үгез.



Ат аптырап калмаган һәм Үгезгә әйткән:

- Менә сиңа, дустым, дуга һәм камыт. Бүгеннән дус икәнемне оныт!

Шулай дигән дә, Ат, борылып китеп барган. Ә Үгез авызын ачып калган.

**Идея авторы**
**Мухаметшина Арина**



**Виеру Григоре Павлович**
**«Иртәнге чык белән ипи»**

Дору бик кечкенә чагында өстәл артында һәрвакыт көйсезләнә иде: я моны ашыйсы килми, я - тегене.

Бервакыт әнисе Дорудан сорады:

-Ипи белән май ашыйсың киләме?

-Юк!

-Ә ипи белән варенье?

-Теләмим!

Әтисе аларның сөйләшүен ишетте һәм сорады:

-Ә синең иртәнге чык белән ипи ашыйсың киләме?

-Нәрсә белән?- Дору аңламады.

-Иртәнге чык белән.

Дору нәрсә дип җавап бирергә дә белмәде. Аның беркайчан да иртәнге чык белән ипи турында ишеткәне булмады.

-Иртәнге чык белән ипи ашарга телим! Телим!

-Яхшы, -диде әтисе. -Ләкин сиңа иртәнгә кадәр көтәргә туры килер. Чык виноград басуында иртән генә була.

Доруны әтисе бик иртә уятты. Алар виноград басуына киттеләр. Ә басу өстендә кояш әле күтәрелмәгән иде.

-Иртәнге чык белән ипи кайда?- дип сорады Дору.

-Көтеп тор, -диде әтисе. -Әлегә көрәк ал. Әйдә эшләп алыйк. Кояш күтәрелгәч, иң яхшы чык булачак. Әтисе виноград куагы астына иртәнге аш - ипи, сыр һәм суганны куйды. Аннары улына кечкенә көрәк тоттырды, ә үзенә зурын алды. Алар эшли башладылар.

Дору куак тирәсендә җирне йомшарта, әтисе дә.

Дору җирдән виноград ботакларын күтәрә, әтисе дә. Алар эшлиләр!

-Ә иртәнге чык белән ипи? -дип сорый Дору. - Минем ашыйсым килә!

Бу вакытта виноград басуы өстендә кояш күтәрелде, ә әтисе белән улы инде эшләп өлгерделәр.

-Хәзер ашарга да ярый, -диде әтисе.



Доруга бер кисәк ипи сузды, ипи өстендә чык тамчылары ялтырый иде.

-Я, ничек, ипи тәмлеме? -дип сорады әтисе һәм өстәп куйды: -Иртәнге чык белән?

-Тәмле, -диде Дору. -Чынлап та, бик тәмле!

**Татар теленә тәрҗемә -**
**Газизова Мерием**
**10 сыйныф**

***Республика фәнни-гамәли конференциясендә призлы урын алган яңа ел чыршысы турында хикәят. Автор - Салимуллина Софья, 5нче сыйныф***



**Яшел чыршы, басып торчы, урман түрендә...**

Татарстанның иң матур бер җирендә – Лаеш районының Идел һәм Кама елгасы кушылган урында – бер кыз яшәгән ди. Аның исеме дә бик матур булган – Суфия! Суфия әти-әнисе белән урманга еш барган, чөнки урман аларның авылы янында ук урнашкан икән. Урманда күп төрле агачлар, җиләкләр, гөмбәләр үскән. Ак күлмәкле каеннар, төз наратлар, карт имәннәр һәм яшел чыршылар кызны үзләре дә көтеп алганнар. Чөнки Суфия бервакытта да урмандагы үсемлекләргә зыян китермәгән, агачларны сындырмаган, күбәләкләрне аулаган. “Яшь урманчылар”мәктәбендә табигатьне сакларга кирәклеген бик яхшы аңлаттылар укучыларга.

Җәйләр үтте, көз артыннан кыш та килде. Көтеп алган Яңа ел бәйрәме җитте. Укучылар ныклап бәйрәмгә әзерләнә башладылар. “Яшь урманчылар” бу уку елында тере чыршы урынына ясалма чыршы бизәргә уйлаган иделәр. Ләкин соңга калган булып чыктылар. Бәйрәм алдыннан аларны мәктәптә төбеннән үк киселгән урман гүзәле – яшел чыршы каршы алды. Укучылар бик күңелсезләнсәләр дә, берни эшләр хәл юк, бәйрәм итәргә кирәк иде. Ә безнең Суфиябыз тиз генә яшь урманчы дусларын җыйды да, аларга нәрсәдер аңлатты. Кулларын болгый-болгый сөйләде, чыршының күз яше агып чыккан җирен күрсәтте. Агачның гәрәбәдәй яшьләре кәүсәдә катып калганнар. Бу аның: “Кешеләр, өзмәгез безнең гомерне, кисмәгез безне, аермагыз туган йортыбыздан!”,- дип әйтүе иде.

Менә бәйрәм башланды. Залга матур костюмнар кигән укучылар җыелды. Тик өченче сыйныф укучылары гына күренмәде. Бераздан ишек шакыдылар. Бер-бер артлы аю, төлке, тиен, куян, тукран һәм керпе киемнәре кигән “Яшь урманчылар” керделәр. Барысы да гаҗәпләнеп аларга карады. Бүләкләүләр, җыр-биюләр тәмамлангач, Суфия үзенең дуслары белән чыршы янына килеп басты.

-Хөрмәтле өлкәннәр, укучылар, сезгә әйтәсе сүзебез бар. Урманда яшәүче җәнлекләр һәм кошлар өчен яшел чыршы яшәү урыны да, азык чыганагы да. Ә сез аларны кисеп, табигатькә зур зыян китерәсез, урман халкын йорт-җирсез калдырасыз. Әйдәгез моннан соң ясалма чыршылар гына бизик. Ә яз җиткәч, киселгән бер чыршы урынына алты яшь чыршы утыртыйк. Урман – безнең яшел дустыбыз, кислород чыганагы. Ә чыршы һәм нарат кыш көне дә һаваны кислородка баета. Сез килешәсезме?

Шулвакыт зал көчле алкышларга күмелде. Бу ризалык билгесе иде..

Төнлә Суфиябыз төш күрде. Төлке, тиен һәм тукран, өметле күзләрен аңа төбәп, шат елмаялар иде. Кыз үзе дә аларга карап елмайды, күз кысты. - Бар да яхшы булыр, “Яшь урманчылар” сезне саклар һәм яклар дип әйтәсе килде аның.



***Софья сыйныфташлары белән “Эколята” түгәрәгенә йөри.***

**Кабан күле хикмәте**


Борын-борын заманда да түгел, безнең заманда Кабан күле төбендә Хәзинә шәһәре булган. Күлнең суы бик чиста һәм үтә күренмәле булган. Яр буенда зифа камышлар үскән, талларда сандугачлар сайраган, суда аккошлар һәм үрдәкләр йөзгән. Хәзинә шәһәре Кабан күленең нәкъ уртасында – Казан ханы байлыгын яшергән урында булган. Ә шәһәр халкы – төрледән-төрле балыклар, кыслалар, әкәм-төкәмнәр булган. Алар бик тырышып эшләгәннәр, дус яшәгәннәр ди. Эшләп арганнан соң, күлнең көмеш суларын чәчрәтеп уйнаганнар, биегәннәр, күңел ачканнар. Шәһәрнең исеме җисеменә бик тә туры килгән. Бөтен нәрсә алтын да көмеш икән. Зиннәтле сарайлар, кибетләр, балалар бакчалары, мәктәпләр – барысы да кояш нурларында ялтырап торганнар.

*Дәвамы 4 биттә*

## Кабан күле хикмәте *(Знче биттә башлана)*

Бу шәһәрнең бер аермалы ягы да бар икән: монда беркем дә авырмый ди. Барсы да сәламәт булгач, даруханәләр дә, хастаханәләр дә кирәкми икән. Шәһәрдә йөзү чемпионатлары, олимпиадалар еш булган. Ярышларга Болактан һәм Иделдән чуртаннар, сазаннар, карплар килә икән. Ләкин Хәзинә балыклары һәрвакыт беренче урын алганнар. Чөнки алар чиста сулы күлдә яшәгәннәр, шуңа күрә көчле, житез булганнар. Шулай итеп Хәзинә шәһәренең даны еракларга таралган. Барсының да бу күлгә күчеп киләсе һәм сәламәт яшисе килә икән.

Ә бер көнне шәһәргә кайгы килгән. Никтер алтын-көмеш сарайлар ялтырамый, кояш нуры да күренми ди. Күлнең суы болганган, әллә нинди сасы исләр чыккан ди. Авыруның нәрсә икәнен дә белмәгән балык балалары хәлсезләнеп урынга ятканнар. Йөрүче булмагач, бакчалар, мәктәпләр ябылган. Бик күпләр күршедәге Урта Кабан күленә күчеп киткәннәр. Аларның ничек тә исән каласылары килгән.



Беркем бернәрсә аңламаган. Дәвалаучы булмагач, бик күп халык үлеп беткән ди. Баксаң, Кешеләр яр буенда сабын-порошок заводы төзегәннәр икән. Ә заводның шакшы суын күлгә түгәләр ди. Балыклар телсез булгач, Кешеләргә бернәрсә дә аңлата алмаганнар. Акрынлап Хәзинә шәһәре ләм белән капланган һәм бөтенләй югалган. Шәһәр белән бергә күл өстендәге аккошлар да, үрдәкләр дә юкка чыккан, аларның сасы исле суда йөзәселәре килмәгән. Шулай итеп, көмеш сулы Кабан күле бөтенләй буш калган. Ниһаять, Кешеләр үз хаталарын аңлаганнар, пычрак суны күлгә түкми башлаганнар.

Ә бүген Хәзинә шәһәре ни хәлдә дисезме? Әйе, исән ул, шулай ук гөрләп яши. Балыклар июнь аенда үтәчәк чемпионатка бик тырышып әзерләнәләр ди. Яр буенда мин дә булдым, ике балыкның сөйләшкәннәрен тыңладым. Ишеткәннәремне сезгә дә сөйләдем. Ә сез башкаларга сөйләгез.

**Волкова Резидә Шамил кызы**

## Бинго-бинго

Яңа 2025 елга санаулы көннәр генә калып бара. Син аны кайда һәм ничек каршы алырга уйлыйсың? Уйлап бетердеңме инде? Без синең өчен Яңа елда эшләнергә тиешле эшләр исемлеген төзедек. Аларны башкарсаң, Яңа ел төне дә бик тиз килеп житәчәк. Хыялларың якты, эшләрең һәрвакыт уң булсын!

1. Яңа ел чыршысын бизә.
2. Кышкы урамда һәм урманда фотосессия ясa.
3. 2025 елга максатларыңны яз.
4. Кар көртләрендә йөреп, бияләйләрең юешләнгәнче, кар атышып уйна.
5. Шугалакта тимераякта йөр.
6. Каникулда карарга фильмнар исемлеген барлап куй.






## Зимняя красота

Зима пришла в наши края,
Укрыла снегом все поля,
Посеребрила инеем,
Узоры в окнах синие.
Остановись, замедли бег –
Здесь волшебство, мороз и снег.
Здесь минус 20, царство льда,
И холода, и холода!
Минута – и уже сугроб,
Не видно зданий и дорог.
Вот так, не замечая никого,
Теперь здесь снег главней всего!

## Кышкы матурлык.

Үзенең кар-бураннары белән салкын кыш килде. Басу-кырлар кар астында калды. Агачларны ак бәс каплады. Суык та калышмады: өй тәрәзәләренә матур-матур бизәкләр төшерде. Кыш, әйтерсең, әкияти дөнья. Ап-ак кар, битне чеметүче салкыннар, күз ачкысыз бураннар дөньясы. Әйтерсең лә, салкын кышта, мизгелгә генә булса да вакыт туктала. Тирә-юнь аклыкка, сафлыкка күмелә. Нинди матур булып кар ява! Бөтереләбөтерелә яуган карлар, җәймә булып, җир өстенә ята. Бии-бии күктән төшкән кар бөртекләре күзне иркәли. Тирә-якта - кышкы матурлык, сихри матурлык!

**Хакимова Гөлшат**
**8 сыйныф**

Ёлочку красивую
Домой мы принесём.
Поставим, приукрасим,
Игрушки поднесём.
Ёлочку мы нашу
Гирляндой обмотаем,
Игрушки мы повесим
И вместе поиграем.
У ёлочки пушистой
Подарки всем подарим.
И с нею мы все вместе
Новый год справляем.
**Нургалеева Зарина**
**4А сыйныф**

***

Снежный лес.
Выпал снег, все побелело!
Посмотришь вверх – там снегири
летят.
Под ногами белый снег хрустит.
С неба падает снежок.
Поиграть аж захотелось.
Позову-ка я друзей!
Будем мы в лесу играть,
Бегать, прыгать и скакать,
Новый год скорей встречать.
**Хорошавина София**
**4А сыйныф**

***

Как-то ночью перед Новым годом,
Когда часы 12 бьют,
В ожидании волшебства
Жду подарок от Деда Мороза я.
Раз - проверила под ёлкой
Свой подарок долгожданный.
Два - сходила, подглянула.
Неужели Дед забыл меня?!
А под утро свершилось чудо!
Не забыл меня Дедуля!
И подарок мне принес!
**Бикбаева Руфина**
**4А сыйныф**

***

Вот и зимушка пришла,
Наступили холода.
Все кругом белым-бело,
Много снега намело.
**Слянтев Радмир**
**4Б сыйныф**

Зима, зима на улице
Метели и бураны!
И ели белые стоят,
Как пушистый снег.
Морозы сильные стоят,
Лед в реке замерз.
А синички, снегири
Ищут себе корм.
Лисы, зайцы, белочки
Морозов не боятся.
Только лишь медведи
Зимой спать ложатся.
Дед Мороз рисует
Зимнюю картину.
Выйду я на улицу
Любоваться ею.
**Яковлев Максим**
**4А сыйныф**

***

За окошком снег идет,
Значит скоро Новый год!
Дед Мороз уже в пути,
Долго к нам еще идти
По заснеженным полям,
По сугробам, по лесам.
Принесет он елочку
В серебряных иголочках.
С новым годом нас поздравит
И подарки нам оставит.
**Лаврентьева Вероника**
**4 сыйныф**

***

Зимушка-зима
В гости к нам пришла.
Вьюгой закружила,
Нас запорошила.
**Чилимова Мария**
**4Б сыйныф**

***

Вот и выпал белый снег,
Наступила зимушка.
Будем вместе мы теперь
Играть и веселиться.
Нарядим нашу ёлочку,
Нарядим мы дом.
Будем ждать Новый год,
Он наступит скоро!
**Измайлова Аселия**
**4Б сыйныф**

Зима такая белая,
Как из альбома лист.
А я такая смелая
Качусь из горки вниз!
**Юсупова Амиля**
**4Б сыйныф**

***

В гости к нам пришла зима,
Вместе с ней пришла метель.
Замела она дома, запушила всю
постель.
Речка уж давно застыла,
Лёд на нас глядит уныло.
Ты бери коньки быстрей!
И беги на лёд скорей!
Да бери смелее клюшку-
Ведь зимой она подружка!
Побеги потом на горку.
Да возьми с собой Егорку.
Чтоб скатиться с ветерком,
А потом домой бегом!
**Яковлев Максим**
**4А сыйныф**

***

Зима, зимушка-зима,
Наступила зимняя пора!
Скоро Новый год, сугробы,
радость,
Можно прыгать в снег холодный!
Медведь старый спать пошел,
А зайчонок прыгал в снег
И к медведю провалился.
И сказал он в тот же миг:
-Ты, Михалыч, спать пошёл?
Новый год уж на носу!
-Заяц, слушай, ты пойми,
Я все лето веселился,
На зиму жирок набрал
А теперь мне спать пора!
- Понял, понял, объяснил,
Все мне стало ясно.
Дядя Миша, ты не спи,
Новый год не упусти!
**Ахметов Рустем 4А класс**

*Син ни теләсәң, шуңа ирешә аласың. Синең һәр көнең мөмкинлекләр белән тулы.*























**Яшь рәссамнар 4а сыйныф укучылары - Яковлев Максим, Айвазян Рач, Нургалеева Зарина, Васильева Елизавета, Волков Кирилл, Гаврилова Ангелина, Бикбаева Руфина, Елизаров Игорь, Маклашова Виктория**

**Рәсем укытучысы - Соловьева Галина Ивановна**

Юлдаш

№5 Декабрь
Баш редактор - Шафигуллин Әмир
Шеф редактор - Шаяхметов Нияз
Корректор - Волкова Резида Шамиловна
Верстка - Волкова Алиса